| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ШЛАНГОВСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ШЛАНГА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

---

Шланга авылы

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

13 декабрь 2024 ел № 43/3

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлеге Советының "Физик затлар мөлкәтенә салым турында" 15.11.2019 елның 45/3 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2024 елның 12 июлендәге 176-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Шланга авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1.Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлеге Советының 15.11.2019 елның 45/3 номерлы «физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына (22.05.2020 № 49/5, 15.11.2022 №21/3 20.10.2023 №31/2, 20.09.2024 №40/1 редакциядә) түбәндәге үзгәреш кертергә:

1) 4 пунктта:

5 пунктчада «, шул исәптән махсус хәрби операция барышында хәбәрсез югалган һәлак булганнарны» сүзләрен өстәргә;

7 пунктчада «, шул исәптән махсус хәрби операция барышында хәбәрсез югалган һәлак булганнарны " сүзләрен өстәргә;

2) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Салым ташламасы РФ Салым кодексының 406 статьясының 2 пунктының 2 бүлегендә күрсәтелгән салым салу объектларына карата бирелми, мондый салым салу объектларында урнашкан гаражлар һәм машина урыннарыннан һәм РФ Салым кодексының 406 статьясының 2 пунктының 2_1 бүлегендә урнашкан урыннардан тыш”.

2. Әлеге карарны Шланга авыл җирлегенең мәгълүмати стендларына, Шланга авыл җирлеге сайтына урнаштырырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар, 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган әлеге карарның 1 пунктындагы 2 пунктчасыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның 1 пунктындагы 1 пунктчасының гамәлдә булуы 2023 елгы салым чорында һәм аннан соңгы салым чорларында физик затларның мөлкәткә салымын исәпләүгә бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Шланга авыл җирлеге башлыгы И.И.Якупов